**Туган ягым**

Мин яратам туган ягымны,

Туып үскән газиз йортымны.

Шау-шу килеп,йөгереп уйнап үскән,

Озын-озын ямьле урамны.

Туган якның җирләре дә йомшак,

Тәмле суы, тәмле ашы да.

Канатланып кайтып кергән чакта,

Рәхәт булып китә җаныма.

Сокланырлык аның табигате,

Саф һавалы иген кырлары.

Баһадирдай көчле егетләре,

Уңган-булган алтын кызлары.

Туган ягым - нинди бөек исем

Зур-зур үрләр яулап киләсең.

Тыныч яши халкың, мул тормышта

Гел шатлыклар генә беләсен.

Мин яратам сине, туган ягым!

Иң кадерле, изге җирем син.

Күңелләргә рухи байлык өстәп,

Мәңге яшә, мәңге балкы син!

*Раилә Гирфанова*